

**Туган тел.**

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

*Габдулла Тукай.*

# Габдулла Тукай
# (1886 – 1913)

- Шагыйрьнең туган ягы — матур табигатьле Казан арты. Ул 1886 елның 26 апрелендә хәзерге Арча районының Кушлавыч авылында туа.
- 1895 елны Габдулланы әтисе ягыннан апасы Уральск шәһәренә алдыра. Монда ул мәдрәсәдә һәм бер үк вакытта өчьеллык рус мәктәбендә укый.
- 1905—1907 елларда аны Казанда, Оренбургта, Петербургта яхшы белә башлыйлар.
- Габдулла Тукай 1907 елның көзенә чаклы Уралъскида яши, аннан Казанга килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Казанда була.
- Сигез ел буена иҗат итү чорында ул ун мең юлдан артык шигырь, кырык-илле басма табак чамасы проза әсәрләре язарга өлгерә.



# Кызыклы шәкерт


- Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор; Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!
- Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә; Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.
- Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
- Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.
- —Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсызул;
- Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!



# Бишек җыры


- Әлли-бәлли итәр бу,
- Мәдрәсәгә китәр бу,
- Тырышып сабак укыгач,
- Галим булып җитәр бу.
- Йокла, угълым, йом күзең,
- Йом, йом күзең, йолдызым;
- Кичтән йокың кала да,
- Егълап үтә көндезең.
- Әлли-бәлли көйләрем,
- Хикәятләр сөйләрем,
- Сиңа теләк теләрем,
- Бәхетле бул диярем.
- Гыйззәтем син, кадрем син,
- Минем йөрәк бәгърем син,
- Куанычым, шатлыгым
- Тик син минем, синсең, син!

# Су анасы



Җәй көне .Эссе һавада
мин суда коенам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам,
башым белән суны сөзәм.
Шул рәвешчә бер сәгать ярым
кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез
тирләмәм дип уйлагач,
Йөгереп чыктым судан,
тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән,—
юк янымда юлдашым.
Бервакыт китәм дигәндә,
төште күзем басмага;
Карасам: бер куркыныч
хатын утырган басмада.
Көнгә каршы ялтырый
кулындагы алтын тарак;
Шул тарак берлән утыра
тузгыган сачен тарап.
Тын да алмыйча торам,
куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы
куе агачларга посып.


*... Тау башына салынгандыр безнең авыл,*
*Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;*
*Авылыбызның ямен, суын тәмен беләм,*
*Шуңа күрә сөям жаным, тәнем белән.*




Г. Тукай 1886 нчы елның 26 нче апрелендә Арча районы Кушлавыч авылында Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Биредә сабыйга ата-ана мәхәббәте бик кыска гына вакыт эчендә кала: ул дөньяга килүгә биш ай да үтми, әтисе вафат була. Әнисе Мәмдүдәне Сосна мулласына кияүгә бирәләр. Бәләкәй Габдулланы авылның Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыгына вакытлыча тәрбиягә калдыралар. Бераздан үз әнисе Габдулланы яңа гаиләсенә алдыра. Әмма бер елдан, 1890 елда Мәмдүдә ханым да үлеп китә. Бала бөтенләй ятим кала. Әнә шуннан шагыйрьнең газаплы, авыр тормышы башлана.

Бала чакта ук ана мәхәбәтеннән мәхрүм булып, җылы кул сыйпавын күрмәгән һәм тамагы ашка туймаган сабыйның кулдан-кулга, кешедән-кешегә күчеп йөрү еллары аның күңелендә төзәлмәслек яра калдыралар. Шуңа күрә дә Тукай иҗатында бәхеткә, мәхәббәткә сусау хисләре, йөрәк тетрәткеч шигырь юлларына әвереләләр.

# Тукай Кушлавычта





Тукай Кушлавычта икенче мәртәбә 1894 елда була: Уральскийга китәр алдыннан ул биредә туганнарының берсенең өендә бер ай чамасы яши.


Тукаевларның Кушлавычтагы музей-йорты Мөхәммәтгариф мулланың йорт-җире урынында, элеккечә итеп, яңадан торгызылган.

Музей экспозициясендә шагыйрьнең ата-анасы йорты, ишек алды, каралты-курасы, ул замандагы йортның эчке күренеше күрсәтелгән. Бүлмәдәге бик күп әйберләр уңган һәм тырыш хатын-кызлар кулы белән эшләнгән. Анда шулай ук әтисенең шәхси әйберләре куелган. Музей йортның ирләр ягында - мөселман руханиларның эшчәнлеге, хатын-кызлар ягында традицион татар авыл өе чагылдырылган.

Тукайның үлемсезлеге - аның шигырьләрендә. Шагыйрь тормышы белән бәйле һәр урын, аның истәлеген саклаучы һәр музей аны безгә тагын да якынайта.

Габдулла Тукай татар халкының бөек шагыйре. Ул калдырган иҗат мирасы һәм андагы рухи яктылык - безнең мактанычыбыз һәм горурлыгыбыз. Без Г. Тукайны беләбез, яратабыз, өйрәнәбез. Безнең телебез Тукай шигырьләре белән ачыла һәм аның моңсу тавышлы шигырьләре гомеребез буе хәтеребездә сакланачак.

# Тукай Кырлайда




Габдулла Тукайны бәләкәй вакытында үзенә сыендырган Яңа Кырлай авылы үзе үк мемориаль һәйкәл булып тора. Кырлай авылында Сәгъди абзыйлар гаиләсендә Тукай 5 елга якын яши. Тукайның гади крестьян тормышының көндәлеге, ихтыяҗын сиземләве шушы Кырлайдан башлана. Монда ул мәдрәсәгә йөреп белем ала, халык иҗаты гәүһәрләре белән таныша. «Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным», - дип язды соңыннан шагыйрь.

Шагыйрь эзләре калган сукмаклар авылда әле дә саклана. Аларнын берсе Тукай мемориаль комплексына алып килә. Музей 1979 елның 25 апрелендә ачыла.

Музей Тукай үзенең бик күп шигырьләрен багышлаган елга буена урнашкан, ул ерактан күренеп тора. Музейга берничә юл белән барып була. Туры сукмактан, бөдрә каеннар утыртылган юлдан да барып була. Музейга кунакка килүче һәркем биредә агач утыртып калдыра, һәм музейга бу юлдан да барып була. Бу - дуслык Аллеясы .



Музей каршында безне Тукай һәйкәле каршы ала. Әйтерсең, шушы йортка керер алдыннан Тукай ял итәргә уйлаган. Бөек Тукаебызның тормыш юлы бик тә кыска һәм авыр булган.

# Тукай – күпкырлы талант

Кырлай музее экспозициясе шагыйрьнең бөтен тормыш юлын гәүдәләндерә: экспонатлар арасында Тукайның үзе исән чакта басылган китаплары, аның туганнары һәм дусларының шәхси әйберләрен, Казанның «Болгар» кунакханәсендәге җиһазларны күрергә мөмкин.



Тукай - күпкырлы талант. Ул - шагыйрь, туган як табигатенә гашыйк, жир йөзендә яшәүче һәркемнең ирекле һәм азат булуын тели. Шул ук вакытта - ул үткен телле сатирик та, ялганчыларның, идарә итүчеләрнең, руханиларның ике йөзлелеген фаш итә. Тукай иҗатының иң югары ноктасы булып «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасы тора. Шагыйрь анда искелек калдыкларын, дорфалык, наданлыкны тәнкыйтьли. Тукай - публицист та, тормышның иң мөһим проблемаларын мәкаләләрендә күтәреп чыга.






# Г.Тукай иҗаты буенча тест сораулары

**1.Г.Тукай халык әдәбияты турында лекцияне кайчан, кайда укый?**
а)1909 ел.25 май Укытучылар йорты.
б)1910ел. 15 апрель Шәрыкъ клубы.
в)1912 ел. 20 март Болгар гостиницасы.

**2.Г.Тукай 1911 елның маенда кайсы шәһәргә килә?**
а)Мәскәү
б)Пермь
в)Әстерхан

**3.Әстерханда Тукай кемдә яши?**
а)М.Галәү
б)С.Сүнчәләй
в)С.Рәмиев

**4.Г.Тукайның "Государственная Думага" шигыре нинди жанрда язылган?**
а)нәсер
б)памфлет
в)мәдхия

**5.Г.Тукайның "Пәйгәмбәр" шигыре нинди иҗат юнәлешендә язылган?**
а)романтизм
б)реализм
в)модернизм

**6.Г.Тукайның "Пар ат"шигыре нинди эчтәлекле?**
а)тәнкыйди
б)реалистик
в)романтик

**7.Г.Тукайның"Өзелгән өмид" шигыре нинди лирикага карый?**
а)модернистик
б)реалистик
в)романтик

**8.Г.Тукайның" Эш беткәч уйнарга ярый"әсәре ничәнче елда басылган?**
а)1906
б)1909
в)1910

**9.Г.Тукайның "Көзге җилләр"шигыре беренче мәртәбә кайда һәм кайчан басыла?**
а)Вакыт 1912ел
б)Йолдыз 1911ел
в)Нур 1907ел

**10.Г.Тукайның "Туган тел"шигыре беренче басылган җыентыкның исеме?**
а)Әдәбият
б)Балалар күңеле
в)Күңелле сәхифәләр